ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 август 2026ел № 8296

Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5119 номерлы Карары белән расланган рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 7 октябрендәге 5119 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 12 мартындагы 1713 номерлы, 2023 елның 20 апрелендәге 3186 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның ундүртенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 29 маендагы 781 номерлы Карары (алга таба - Җирләрне рекультивацияләүне үткәрү кагыйдәләре) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 22 (I өлеш), ст. 2898, 02.06.2025);»;

2) 1.5 пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«җирләрне рекультивацияләү – җирләрне максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерү ярдәмендә, шул исәптән туфрак пычрану нәтиҗәләрен бетерү, туфракның уңдырышлы катламын торгызу һәм агроурманмелиоратив утыртмалар, агрофитомелиоратив утыртмалар булдыру юлы белән җирләрнең деградацияләнүенә юл куймау һәм (яки) аларның уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар;»;

3) 2.1 пунктта «РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы Карары» сүзләрен «Җирләрне рекультивацияләүне үткәрү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2.3-2.5 пунктларда «РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы Карары» сүзләрен «Җирләрне рекультивацияләүне үткәрү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

5) 2.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җирләрне рекультивацияләү проектында каралган чаралар Җирләрне рекультивацияләүне үткәрү кагыйдәләренең 5 һәм 6 пунктларында каралган җирләрнең сыйфатын тәэмин итмәячәк;<br>2) җирләрне рекультивацияләү проектында каралган рекультивацияләнә торган җирләрнең һәм җир участокларының мәйданы җирләрне рекультивацияләүне үткәрү таләп ителә торган җирләр һәм җир участоклары мәйданына туры килми;<br>3) җирләрне рекультивацияләү проектының «Аңлатма язуы» бүлегендә рекультивацияләнә торган җирләр һәм җир участоклары турында дөрес булмаган мәгълүматлар булу | Җирләрне рекультивацияләүне үткәрү кагыйдәләре |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов